
ISSN 0868-4545




# Салават күпере

Яңа ел килде
Бүген безгә дә!






Күзләр шардай,
Карбыз балдай.
Карбыз бетә —
тагын давай!




Биюченең итәге
Бии-бии кыскара.
Биючегә сүз әйтмәгез,
Бии-бии остара.




Ай үсәсен көн үсәмен,
Көн үсәсен сәгатьтә.
Көнгә өч банка варенье
Бик аз инде, әлбәттә!








Зурларга да, безләргә дә
Кагылды заман җиле...
«Яңа татар малае» мин —
Таныгансыздыр инде?!




Мактанырга һич яратмыйм...
Мин — бик ыспай, көяз мин...
Кукмараның, Зур Сәрдекнең
Шаһзадәсе Нияз мин!




Ник гаҗәпкә калдың әле,
Ник аларттың күзләрең?
Юкмы әллә синең бер дә
Гулливерны күргәнең?!

© "Салават күпере", 1999 ел

# Бәйрәм булып кил

*Безгә әкиятләр һәм мультфильмнар аша таныш ул. Аны җиде башлы дип тә, өч башлы дип тә, авызларыннан ут бөркүче дип тә беләбез. Ул дигәнебез аждаһа була инде. Нигә әле тиктомалдан аждаһаны искә төшердек соң? Тиктомалдан түгел лә икән... Чөнки... чөнки... киләсе елда ул безгә килә. Яңа ел булып, Аждаһа елы булып.*




*Аждаһа елы ул безнең өчен шуның белән дә истәлекле булыр: «Салават күпере» журналына мартта 10 яшь тула. Бу көн – барчабызның уртак бәйрәме. Һәр көнең бәйрәм булып килсен, Аждаһа елы!*

Рәссам Юрий ДЕНИСОВ




Ләбиб Лерон

# Суперчана

Чана ясадым. Шәп килеп чыкты — искиткеч! Әйбер-сәйбер ясарга оста инде мин шулай. Коеп кына куям. Әйткәнем шул — синең сәләмә чанаң янында минем чана — галәмәт!


Шуганда җайлы булсын өчен дип, чанага йомшак утыргыч белән иске виләсәпиднең рулен беркеттем. Каршыга очраганнарны кисәтер өчен рулгә кыңгырау куйдым. Чананың алдында да, артында да бәтәрәй белән эшли торган яктырткычлар барлыгы турында әйтеп тә тормыйм. Караңгы төшкәч тә шуган чакларны истә тотып куйдым аларны. Кечкенә букча эләргә дә урын таптым. Букчада — май ягылган ипи белән термос. Термоста – мәтрүшкәле кайнар чәй... Тагы... Ә-ә-ә, күзгә барлыгын әйтергә онытып торам икән. Кыскасы, минем чана – суперчана! Тауга выжылдап шуып менеп китәсең – артта җил генә кала да сызгырып, карлы буран гына кала ыжгырып. Сизеп торам, синең колакларың тырпайды: «Ничек инде... Таудан шуып төшәләр, тауга шуып менмиләр...» — дисең. Шу син үзең сәләмә чанаң белән түбән таба. Ә минем чана... Минем чана — тауга шуып менә торган чана! Шуңа күрә, чанага тормоз да куймадым мин. Тау менгәндә тормоз кирәкми. Иллә дә җилдереп менә инде чанам. Шул чагында магнитофоннан җыр да тыңлап җибәрсәң:

...Керкәле таулары биек,
Биек булса да меник...

Телисеңме, мин сиңа шушы суперчанамны җәлләмичә бирәм. Миннән бүләк булыр үзеңә. Йөрмә ул сәләмә чанаңны өстерәп...

Үземнеке шикелле чананы мин сиңа йөзне ясап бирә алам. Юк, меңне! Миллиунны!.. Рәсем ясарга оста мин. Кәгазь белән бу́яу гына җитсен.






Рәссам Иван ВОРОБЬЕВ






Самуил Маршак
Мин күрдем
Күп күрдем мин, күп күрдем:
Ут эчендә күл күрдем,
Чалбар кигән эт белән
Атка атланып йөрдем.
Барысын да мин күрдем:
Эшләпәле өй күрдем,
Эшләпәле өй күрдем,
Мәчеләрне куып йөргән
Тычканны да мин күрдем.
Төлке белән үрдәкнең
Кабартма пешергәнен,
Йөнтәс аю малаеның
Башмак киеп йөргәнен... —
Барысын да мин күрдем...
Ниләр күрсәм, җүләр күк,
Чынлап ышандым үзем!
Урысчадан Ләбиб Лерон
тәрҗемә кылды.
Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ

**Нәкыйп Каштан**

# Канатлы ай

Кич. Авыл тынлык куелыгына чумган. Үзе шундый җылы. Өйгә һич керәсе килми. Капка төбендәге утыргычта, кичке шәфәкъ матурлыгына хозурланып, әнисе белән нәни Фирая сөйләшеп утыра. Утыра дигәч тә, утыргычта әнисе генә утыра, ә аның итәгенә Фирая менеп кунаклаган.

Күк гөмбәзендә учлап сибелгән энҗе-мәрҗәннәрдәй йолдызлар җемелди. Аларның барысын да уздырып, түм-түгәрәк ай көмештәй нурларын җиргә сибә, гүя ул шулай Фираяны сөеп елмая. Айның ике ягында да, аккош канатларыдай, нәфис каурый болытлар йөзеп йөри. Тулган ай менә-менә канатланып очып китәрдәй тоела. Әнисенең итәгендә иркәләнеп утырган Фирая да, әлегә сихри күренештән әсәрләнеп, соклану тулган күзләрен күк гөмбәзеннән ала алмыйча:


— Әни, әни, әнием, кара әле! — ди. — Кара... әнә анда, күктә, ак канатлы Ай йөзә. — Талпына-талпына нәни кулларын чәбәкли. — Канатлы Ай!..

Әнисе дә Айга карый.

— И-и-и, кызым, рәхмәт төшкере! Искиткеч нурлы икән шул кичке Ай. Гаҗәп икән. Кызлар шикелле елмая. Гомеремдә дә мондый Айны күргәнем юк иде. Гомеремдә дә. Бәхеткә генә була күрсен мондый хозур, мондый матур күренеш, — дип үз нәүбәтендә, хыялый, күбәләктәй канатланган нәни кызына карап, нурлы Айдай елмая.

Әйе шул, әниләр янында Ай да канатлы.

*Рәссам Светлана ПРИВИНА*





**Сәхифәбездә кунакта — Казандагы 111 нче мәктәпнең яшь каләм ияләре. Алар «Сәйләннәр» әдәби-иҗат берләшмәсенә (остазлары — шагыйрә Резеда апагыз Әхтәмова) бик теләп, сөенеп йөриләр. Синең игътибарга аларның тәүге иҗат җимешләрен тәкъдим итәбез.**



## Куян

*Ап-ак кардай*
*Ап-ак куян.*
*Ничек шулай,*
*Кемгә охшап,*
*Ап-ак булган.*
*Ак кар өстеннән*
*Безнең ак куян*
*Чаба башласа,*
*Бер дә туктамый,*
*Бер кем дә аны*
*Куып тоталмый.*
*Шаян ул куян,*
*Наян ул куян.*
*Кемгә охшап соң*
*Бу җитез куян,*
*Һай, куркак булган?!*

Энҗе Минхасапова



## Ак тәпи

*Бик матур безнең мәче,*
*Бик матур күзле мәче.*
*Тәпиләре шундый ак –*
*Яңа яуган кардан пакь.*
*Төн буе мич эчендә*
*Безнең мәче җылына.*
*Иртә белән ул аннан*
*Кап-кара булып чыга.*

Энҗе Мусина

## Кыш

*Җиргә кыш килә,*
*Ак карлар иңә.*
*Кышның салкыны*
*Йөзләргә сеңә.*
*Тик без салкыннан*
*Куркып тормыйбыз –*
*Иртә-кичләрдә*
*Тауда уйныйбыз.*

Алисә Шәрәпова



Бу рәсемнәрнең авторлары —
Казандагы 141 нче мәктәп
(Дәрвишләр бистәсе) укучылары.
Сурәтләргә игътибар ит әле:
ниндидер сер-тылсым бар сыман аларда...

Катя Агеева

Динә Җиһаншина

Максим Евдокимов

Дима Бородулин





**Ренат Мәннан**

## Үгезгә киңәш

Ун, тугыз, сигез —
Әй, симез үгез.
Җиде, алты, биш —
Бүре килә ич!


Дүрт, өч, ике, бер —
Тиз качып өлгер!

Йөз, туксан, сиксән —
Калырсың исән.

Җитмеш, алтмыш, илле —
Җәтрәк кач инде.

Кырык, утыз, егерме —
Әйтмәдең димә, яме?!

Ун —
Абзарыңда кун!





**Хәкимҗан Халиков**

## Охшаткан

Һашим беркөн урамда
Алма ашап йөргән, ди.
Аны чучка күргән, ди,
Шундук чабып килгән, ди.

— Кем чапылдата, дисәм,
Һашим, син икән,— дигән. —
Син дә безнең шикелле
Ашыйсың икән,— дигән.

*Рәссам Сергей АНДРИАНОВ*

# Иң матур ил

Газинур Морат шигыре
Наил Нәбиуллин көе

*Бакчада без шундый бер җыр өйрәнгән идек,*
*Иң матур ил — безнең ил, дип көйләгән идек,*
*Ә бүген бергәләп шундый фикергә килдек:*
*Безгә туган телебезне онытырмаган,*
*Безнең шәҗәрә агачын корыттырмаган*
*Ил генә һәрвакыт безнең яклы ил була.*
*Шундый ил генә хөр, матур, якты ил була.*

(Җырның тиз темплы өлешен 2 нче тапкыр кабатлаганда соңгы 2 такт сузып бетерелә.)

**Салмак**

Бак-ча-да без шун-дый бер җыр өй-рән-гән и - дек,
Иң ма-тур ил – без-нең ил, дип көй-лә-гән и - дек,
Ә бү-ген бер - гә-ләп шун-дый фи-кер-гә кил - дек:
Шактый тиз.
Без-гә ту-ган те-ле - без-не о-ныт-тыр-ма - ган,
Без-нең шә-җә-рә а - га-чын ко-рыт-тыр ма - ган,
Ил ге-нә һәр ва-кыт без-нең як-лы ил бу - ла.
Темпны әкренәйтеп.
Шун-дый ил ге - нә хөр, ма - тур, як-ты ил бу- ла.

*Рәссам Галина РАСЧЕСКОВА*

*Инглиз телен өйрәнүче дускай!*
*Менә син Г.Тукай «Шүрәле»сенең башлам өлешен инглиз телендә дә укыдың (әсәрне Казан дәүләт педагогия университеты доценты Алсу Фоат кызы Вәлиева тулысынча тәрҗемә итте). Бәлки үзеңдә дә «Шүрәле»нең дәвамын инглизчә «сөйләштереп» карау теләге уянгандыр?! Уңышлар телибез сиңа.*

**Габдулла Тукай**






(Башы 1999 елның 9 нчы санында)

**Юкә, каеннар төбендә кузгалаклар, гөмбәләр**
**Берлә бергә үсә аллы—гөлле гөлләр, гөнҗәләр.**

**Ак, кызыл, ал, сап—сары, зәңгәр, яшелдән чәчкәләр;**
**Һәр тарафка тәмле исләр чәчкәли бу чәчкәләр.**

**Үпкәлиләр чәчкәләрне төрле төсле күбәләкләр**
**Килеп, киткән булып, тагын да шунда чүгәләп.**
**Бервакыт чук—чук итеп сайрый ходайның кошлары;**
**Китә җаннарны кискәләп, ярып садаи хушлары.**

**Монда бульварлар, клуб һәм танцевальня, цирк та шул;**
**Монда оркестр, театрлар да шул, концерт та шул.**

**Зур бу урман: читләре күренмидер, диңгез кеби,**
**Биниһая, бихисаптыр, гаскәре Чыңгыз кеби.**

**Кылт итеп искә төшәдер намнары, дәүләтләре,**
**Карт бабайларның моны күрсә, бөтен саулатләре.**
**Ачыла алдыңда тарихтан театр пәрдәсе:**
**Аһ! дисең, без ник болай соң? Без дә хакның бәндәсе.**

**G.Tukai "Shurale"**

Translated from Tatar by Valeyeva Alsu.

**There beneatch the birches and oak-tress many mushrooms, berries grow,**
**Charming buds and pretty flowers make a wreath of splendid bows.**

**Red and green and white and yellow, blue and purple in the sun,**
**Flowers growing everywhere are the greatest of the fun.**

**On the tender leaves and flowers butterflies will lightly fly,**
**Kiss the petals, touch the brightest as if wish to say good-bye.**

**In the golden heat of summer bluebells ring their ding-ding-dongs,**
**And the heaven's birds are singing their sweet and lovely songs.**

**See the boulevards and the squares, clubs and scene and after all -**
**On the grassy glade forever a fantastic dansing hall!**

**Mighty forest is like ocean. Where do borders here run?**
**And the trees are standing there like the troops of Djengiz chan.**


**Look around - everywhere on the roads so wide and vast**
**See unfaded trace of glory of the great grandfather's past.**

**And before your eyes the curtains of the history will raise...**
**Oh! - you'll say. Why are so aimless modern generation days?**



Рәссам Фәрит МУЛЛАХМӘТ





А.И. Иванов. **Остаханә күренеше.**
Майлы буяу

А. Матисс. **«Кызыл балыклар».**
Майлы буяу






## НӘКЫШЬ (живопись)

Бу биткә күз төшереп кенә алыгыз да, башыгызны күтәреп тирә-юньгә күз салыгыз. Без төсләр дөньясында яшибез икән бит. Ул төсләр төрле яктылыкта төрлечә була, үзгәрә. Хәтта безнең кәефебезгә карап та үзгә күренә. Менә шул төсле дөньяны буяулар һәм пумала белән яссы өслеккә — киндергә яки картонга (кәгазьгә түгел!) күчерүче рәссам **нәкышьче** була.

Нәкышьче остаханәсенең түрендә **мольберт** тора. Рәссам рамланган киндерне шуңа беркетеп куя һәм бер кулына **палитра**, икенчесенә пумала алып иҗат итә. Буяуларны бер-берсенә кушып төсләр таба торган юка такта була ул палитра. Нәкышьчеләр төрле буяулар белән эшлиләр. Хәтта графиклар ярата тор-

А.П. Ткачев. **«Бала-чага».** Майлы буяу



ган акварель һәм гуашь белән дә. Әмма остаханәдә **майлы буяу**лар патшалык итә. Майлы буяу белән ясалган картина ялтырап тора, төсләрен җуймыйча озак саклана.

**Темпера** дигән буяуның гомере тагын да озынрак. Еллар узган саен ул ныгый гына бара. Темпераны элек буяу «оны»на йомырка сарысы кушып ясаганнар. Хәзергеләрендә йомырка булмаска да мөмкин.

Майлы буяу белән иҗат иткәндә рәссам төсләр күчешен бер төсне икенчесенә кушып бирә ала. Ә темпера техникасы бүтән: анда төсләрне бутамыйлар, бер төсне икенчесе янына юка катлам итеп сылап куялар. Якыннан карасаң, каткан буяудан башканы күрмәвең дә мөмкин, ерактан – күз явыңны алырлык әсәр балкый!

Ә хәзер, әйдәгез, инде ашыкмыйча, картиналарны карыйк. Алар – нәкышь сәнгате җәүһәрләре.

**Юлия Щетинкина,**
рәссам.



Рафаэль. **«Конестабиле мадоннасы».** Темпера




К.П. Брюллов. **«Итальян гаиләсе».** Акварель



И. И. Шишкин. **Нарат урманы. («Корабельная роща»).** Майлы буяу

# БАШВАТКЫЧЛАР





**Рәсемнәргә карап алты аерма тап.**




**Сыр кемгә эләгер икән?**

*Рәссам Илдар НӘФИЕВ*

Ринат Нуруллин

# Могҗиза бар бездә дә

Кыска гына әйткәндә,
Арыш үсми чәкәндә.
Ул үсә безнең якта
Басудагы башакта.

Безнең якта кыяр да
Үсми биек кыяда.
Кыяр үсә, һәрхәлдә,
Бакчадагы түтәлдә...

...Ә менә бер әйбердә
Барсы да була бергә:
Яфрак, алма һәм кабак,—
Һич үсмәсә дә сабак.

— Нәрсәдә? — дип сорасаң,
Бары тик шуны ачам:
Сорауга эзлә җавап,
Көмеш көзгегә карап.

Җавап: Безнең башыбызда колак яфраклары, күз алмалары һәм күз кабаклары бар.





# Тәнзия кызыклары



Тәнзия ручка тотып әллә ниләр язып утыра:

— Әни, менә никадәр яздым, начальникка керәм мин!



Тәнзия ботка ашап утыра.

— Асап бетерәм дә, дәү үсәм аннары...

Ботканы ашамыйча китеп барды.

— Ник ашамадың?

— Әй лә, дәү үсәсем килмәде.



Тәнзия песи белән көлә-көлә уйнап утыра!

— Ну, мәче, үтерәсең көлдереп!




Тәнзия юлдан бара.

— Чык кырыйга, тутут килә.

— Түтүт түгел ул, мотоцикл!




Тәнзиянең мәзәкләрен әнисе Фәридә Садриева язып алды (Кече Елга, Лаеш).

*Рәссам Илдар НӘФИЕВ*




Су кызы мин! Яр читенә
Сине күзләп чыгуым.
Үскәч аны кем дә әйтә,
Хәзер әйт син: «Сылуым...





«Әллү! Әллү!» — дия-дия,
Телефоннан сөйләшәбез.



Конкурс! Мин бит бу?!




Апа-сеңел ни сөйләмәс —
Көлешәбез, серләшәбез...




Аяк тибеп, кашык сугып,
Үтенеп сорыйм сездән:
— Бирегез инде ашарга,
Юкса үләм бит тиздән!

Сәләват күпере

11-12(117-118) — 1999

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГЪЛҮМАТ ҺӘМ МАТБУГАТ МИНИСТРЛЫГЫ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ ИДАРӘСЕ ҺӘМ РЕДАКЦИЯ ЖУРНАЛЫ
1990 елның март аеннан бирле чыга

"Салават купере" ежемесячный журнал Министерства информации и печати РТ, правления Союза писателей РТ и редакции. На татарском языке.
Основан в 1990 году.

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы тарафыннан 96 нчы номер белән теркәлде

Баш мөхәррир
Зиннур ХӨСНИЯР

Баш мөхәррир урынбасары
Фирая БӘДРЕТДИН

Бүлек мөхәррире
Ләбиб ЛЕРОН

Бизәлеш мөхәррире
Фәрит МУЛЛАХМӘТ

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

Исәп-хисап бүлеге
Рәмзия САЛИХ

Тышлыкның 1нче битендә
Дамир ҖӘЛӘЛЕТДИНОВ рәсеме

Адрес редакции:
420012 г. Казань, ул. Муштари, 14.


«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

Татарстан газета-журналлар нәшрияты. Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт


Производствога бирелде 14.12.99 ел.
Басарга кул куелды 14.12.99 ел.
Кәгазь форматы 84х108 1/16.
Офсет ысулы белән басыла.
Тиражы 12569 данә. Заказ 3-623.
Бәясе килешү буенча.

POINT®


Бәясе килешү буенча
Индекс 73953




Чәчәкләргә шигырь сөйлим,
Алар мине тыңлап тора;
Шигырь беткәч, «Рәхмәт!» диеп,
Кыңгыраулар чыңлап тора.




Тары боткасы ашасам
Салып тәлинкәләргә, —
Яңакларым бүлтәюгә
Күзләр тәлинкәләнә.




Ике мәче борын терәп
Тәлинкәдән сөт эчә.
Ике мәче кавышканны
Кавышырбыз ничек тә...







Сигез айлык кына бит мин,
Ашый белеп ашамыйм:
Әфлисунның, мандаринның
Кабыгын да ташламыйм.




Кайсыгыз тиде Адельгә?
Бик ачулы чагыбыз:
Өчкә кадәр санаганчы
Тизрәк әйтеп калыгыз!




Әйдәгез, таныш булыйк:
Минем исемем — Эльнара.
Еллар үткәч, кем белә бит,
Очрашырбыз бер ара...